ГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Нефтьчеләр ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» ноябрь 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 24 нояберенә билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 24 нояберендә 2024 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Каменка авылы, Җәлил ур. , 2 нче йорт;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 19 нояберennән дә соңга калмыйча гражданнарга Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Каменка авылы, Җәлил урамы, 1 нчы йорт ; Мәлбагыш авылы Җәлил урамы 2 нче йорт, Түбән Якый авылы Кашапов урамы 23 йорт, Каменка авылы Җәлил урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;
- Каменка торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Каменка торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында, һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә китүчеләрнең гаилә агъзаларыннан, РФ Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү өчен контракт төзегән гаилә әгъзаларыннан тыш Мәлбагыш авыл җирлеге Каменка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 3500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Җәлил урамына вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Мәлбагыш торак пункты территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында , Мәлбагыш авылы Җәлил урамы 2 йорт; Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 нче йорт ; Каменка авылы Җәлил урамы 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башлык: А.Й.Әхмәтшин